Россия Федерациясе
мөселманнары Диния нәзарәте

بسم الله الرحمن الرحيم

# МӨФТИ ШӘЕХ
# РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ
# ГЫЙД ӘЛ-ФИТР — УРАЗА БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
Һиҗри 1443 елның 1 нче шәүвәле
Милади 2022 елның 2 нче мае

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

Рәхмәте киң булган галәмнәрнең Хуҗасы, күк белән җирне бар кылучы, бар мәхлүкат тарафыннан данланучы һәм һәрнәрсәгә рәхимле Аллаһка мактау булсын! Пәйгамбәрләрнең һәм Расүлләрнең соңгысы Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

**Кадерле дин кардәшләрем!**

**Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!**

**Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек,**

**Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм!**

Бүген без ике иң зур мөселман бәйрәмнәренең берсе — Ураза гаетен бәйрәм итәбез.

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте һәм үз исемемнән бар мөселманнарны әлеге олуг бәйрәм белән тәбриклим! Тоткан уразабыз һәм кылган бар игелекле гамәлләребез Аллаһы Раббыбыз тарафыннан кабул ителсен. Аллаһ барыбызны да ике дөнья бәхетенә ирештерсен! Аллаһ үзебезне һәм гаиләләребезне сәламәтлек илә бәхеткә ирештерсен!

Аллаһы Сөбханәһу вә Тәгалә Үзенең Китабында боера:

وَأَطِيعُوا اللَّهَ وَالرَّسُولَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ. وَسَارِعُوا إِلَى مَغْفِرَةٍ مِّن رَّبِّكُمْ وَجَنَّةٍ عَرْضُهَا السَّمَاوَاتُ وَالْأَرْضُ أُعِدَّتْ لِلْمُتَّقِينَ. الَّذِينَ يُنفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ

**“Аллаһка һәм Пәйгамбәргә буйсыныгыз. Шулвакытта гына Аллаһның рәхмәтенә ирешерсез. Аллаһның гафу итүче һәм киңлеге җир вә күк арасы кебек киң. Аллаһтан куркучыларга әзерләнгән җәннәткә керү өчен бер-берегез белән узышыгыз. Ул кешеләр шундыйдыр: барлык вакытында да, юклык вакытында да Аллаһ ризалыгы өчен хәер бирәләр, ярдәмчел булалар, ачуларын йоталар, башкаларны гафу итәләр. Аллаһ адәмнәргә яхшылык итүчеләрне ярата.”** *(“Әлү-Гыймран” сүрәсе, 132-134а.).*

Әлеге аятьләрнең тирән мәгънәсе безгә иманлы кешенең авыр вакытта өметсезлеккә төшмәвен, изге ниятләре тормышка ашмаса, сабырлыгын җуймыйча, тыныч булып, тырышлыгын көчәйтүен аңлата. Узып киткән Рамазан — Аллаһы Тәгаләнең бөек әҗер-савабына ирешер өчен мөэмин-мөселман игелектә күп тырышлык куярга тиешле ай булды. Хак мөселманга

хас булганча, садәка бирергә, үзен Раббысына багышларга, Аллаһның Расүле Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәллам үрнәгенә иярергә, туганнары һәм якыннарына тиешле игътибар күрсәтергә. Ураза бәйрәме — үзеңнең гамәлләреңә нәтиҗә ясый торган һәм шәхси ныклыгың, сабырлыгың һәм үзеңне яхшы якка үзгәртә алуыңа сөенә торган вакыт.

Бу изге айда мөселманга фарыз булган биш гамәлнең берсен — Раббыбыз кушуына буйсынып, ураза гыйбадәтен үтәдек:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا
كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

**“И иман китергән кешеләр! Сезгә, сездән алдагы кешеләргә фарыз ителгән кебек, ураза фарыз ителде. Шулвакыт сез Аллаһтан куркучы булырсыз.”** *(“Әл-Бәкарә” сүрәсе, 183а.).*

Без Аллаһның ярдәменә һәм рәхмәтенә өметләнгән хәлдә, үз-үзебезне тыюыбыз, дога һәм ялваруларыбыз, игелекле гамәлләребез кабул ителәчәгенә ихластан ышанып, бар тырышлыгыбызны куеп, ураза тотарга омтылдык! Без тирә-юньгә яхшылык таратырга, уйларыбызны, хисләребезне, гамәлләребезне төзәтергә мөмкинлек эзләдек.

Ураза тотуның мөһимлеге, аятьтә әйтелгәнчә, бар мөселманга фарыз кылынуында. Безгә кадәр яшәгән буыннар авыр хезмәт башкарып та, иман ныклыгы һәм Раббыбызны ярату үрнәген күрсәтеп, динебездәге төп нигезләрнең берсен үтәргә тырышкан. Безгә исә Аллаһның бу бүләгенең кадерен белергә, Аның Расүле Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлламнән, әби-бабайларыбыздан үрнәк алырга, иманыбызны ныгытырга һәм Раббыбызның кушканнарын ихласлык белән үтәргә кирәк.

Кемнәрдер уйлаганча, уразаның төп максаты ач торуда түгел. Уразаның мәгънәсе күпкә бөегрәк. Мөэмин-мөселман тәгамнән тыелып, мохтаҗларның хәлен яхшырак аңлый башлый, бу дөнья тереклегенә мәрхәмәтлелек тәрбияли һәм зарары тимәслек итеп үз нәфесен йөгәнли. Рамазан ае дәвамында без ураза, өстәмә намазлар, игелекле гамәлләр аша Аллаһ ризалыгына ирешүдә бердәм булдык!

Әлеге изге көннәрдә үзебезне ризык белән судан гына тыймадык, вакытыбызны рухи чистарынуга да багышладык. Без үзебездә тирә-юньдәгеләргә карата хөрмәт сыйфатын камилләштердек. Моны безгә Пәйгамбәребез Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәллам өйрәтеп калдырган:

واللهُ في عَوْنِ العَبْدِ ما كَانَ العبدُ في عَوْنِ أَخِيهِ

***“Кардәшенә ярдәм итүчегә Аллаһы Тәгалә ярдәм итәр…”*** *(Мөслим).*

Бу Рамазанда күбебез якын һәм ерак кардәшләрен

кайгыртып, шул исәптән торган җирләрен ташлап, күченеп килергә мәҗбүр булган кешеләрне дә кайгыртып, гыйбадәтләрен тулыландырды.

Галәмнәрнең Хуҗасыннан изге Рамазанда ихлас һәм чиста ният белән кылынган барлык гамәлләрне кабул итүен, алар өчен фани һәм ахирәт дөньяларының әҗер-савабына күп тапкыр ирештерүен ихластан сорыйбыз вә Аллаһу Тәгаләнең Изге Коръәндә биргән вәгъдәсенә иманып, өмет итәбез:

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ
إِذَا دَعَانِ فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ

**“Минем колларым синнән Минем турында сораса, син аларга әйт: Мин аларга бик якынмын, алар Миңа дога кылсын, Мин шунда ук кабул итәрмен.”** *(“Әл-Бәкарә” сүрәсе, 186а.).*

Пәйгамбәребез Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлламнең сөннәте нигезендә, бу айны тәгәлләүче гамәл — фитр садәкасын тарату. Ул мохтаҗлар файдасына бирелә һәм алар үзләрен читкә кагылган кеше итеп хис итмәсен, ә киресенчә, бәйрәм шатлыгына ирешсен өчен эшләнелә. Мәгълүм хәдисләр буенча:

فَرَضَ رَسُولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم زَكَاةَ الفِطْرِ
طُهْرَةً لِلصَّائِمِ مِنَ اللَّغوِ وَالرَّفَثِ وَطُعمَةً لِلمَسَاكِينِ

**“Пәйгамбәребез Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәллам әлеге фитр садәкасын ураза тотучыга, сөйләгән начар һәм буш сүзләреннән чистарыну, шулай ук мохтаҗларны сыйлау чарасы буларак таратырга йөкләгән.”** *(Әбү Давыт “Сөнән”е).*

Аллаһтан йөрәкләребезне иманда һәм тәкъвалыкта ныгытуын, үзебезгә, якыннарыбызга һәм тирә-юньдәгеләргә хаклыкны ачуын, күңелләребезне сафландыруын сорыйм! Раббыбыздан уразаларыбызны, гыйбадәтләребезне һәм игелекле гамәлләребезне кабул итүен ялварам. Аллаһы Тәгалә барыбызга да Үзенең рәхмәтен ирештерсен иде.

Ураза гаете мөбарәк булсын!

**Вәссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!**

***Ихтирам илә туганлык догасы белән***

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин***

*Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе*